ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

30 сентябрь 2016 ел № 695-р

Яр Чаллы шәһәрендә муниципаль торак фонды исәбен алып бару һәм аның белән идарә итү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 14 маддәсе, Шәһәр Советының 2014 елның 21 февралендәге 29/12 нче карары белән расланган Яр Чаллы шәһәренең муниципаль милек реестры турында нигезнамә, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә

1. Яр Чаллы шәһәренең муниципаль торак фонды исәбен алып бару һәм аның белән идарә итү тәртибен расларга.

2. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәрендә муниципаль торак фонды исәбен алып бару тәртибен раслау турында» 2015 елның 3 апрелендәге 159-р санлы, «Башкарма комитетның 2015 елның 3 апрелендәге 159-р санлы боерыгы белән расланган Яр Чаллы шәһәрендә муниципаль торак фонды исәбен алып бару тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 1 апрелендәге 202-р санлы боерыклары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ГОРОДА НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Управление делопроизводством
Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе

Башкарма комитетның
2016 елның 30 сентябрендәге
695-р санлы боерыгына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең
муниципаль торак фонды исәбен алып бару һәм аның белән идарә итү
тәртибе

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге тәртип Яр Чаллы шәһәренең муниципаль торак фонды исәбен алып бару һәм аның белән идарә итүне гамәлгә ашырганда Башкарма комитет эшчәнлеген билгели.

2. Муниципаль торак фондының исәп объектлары булып түбәндәгеләр тора:

1) торак йорт, торак йорт өлеше;

2) фатир, фатир өлеше;

3) бүлмә.

3. Муниципаль торак фонды объектларының исәбен алып баруның максаты булып җирле үзидарә органнарын муниципаль торак фонды турында тулы һәм дөрес мәгълүмат белән тәэмин итү тора.

2 бүлек. Яр Чаллы шәһәренең муниципаль торак фонды
исәбен алып бару һәм аның белән идарә итү

4. Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе:

1) муниципаль торак фонды объектларын Яр Чаллы шәһәренең муниципаль милек реестрына (алга таба – Реестр) кертү өлешендә Реестр алып баруны гамәлгә ашыра;

2) квартал саен, 20 числодан соңга калмыйча муниципаль торак фонды объектлары хәрәкәте турында мәгълүматны Башкарма комитетның бухгалтерлык хисабы һәм хисаплылык бүлегенә тапшыра.

5. Башкарма комитетның районнар Хакимияте:

1) район территориясендә урнашкан муниципаль торак фонды объектларын исәпкә алуны гамәлгә ашыра;

2) квартал саен, агымдагы айның 10 числосыннан соңга калмыйча муниципаль торак фонды составындагы үзгәрешләр турында мәгълүматны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсенә тапшыра;

3) ел саен, 15 февральдән соңга калмыйча Реестрга үзгәрешләр кертү өчен, муниципаль торак фонды турында мәгълүматны җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсенә тапшыра;

4) район территориясендә урнашкан торак урыннары гражданнар милкенә тапшыруны гамәлгә ашыра;

5) район территориясендә урнашкан муниципаль торак фонды объектларына карата Реестрдан өземтә бирүне гамәлгә ашыра;

6) ел саен, гражданнарга хосусыйлаштыру тәртибендә тапшырылган торак урыннар саны турында мәгълүматны архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсенә тапшыра.

6. Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе:

1) муниципаль торак фондының торак урыннарын торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнарга бирүне гамәлгә ашыра;

2) хуҗалары вафат булган, ә мирас варисларының берсе тарафыннан да кабул ителмәгән торак урыннарын варисесыз калган дип тану һәм шуннан соң муниципаль милек хокукы рәсмиләштерү өчен, әлеге торак урыннарына кагылышлы документларны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсенә тапшыра;

3) муниципаль торак фондын хосусыйлаштыру буенча җыелма статистика хисабы әзерләүне гамәлгә ашыра.

7. Башкарма комитетның бухгалтерлык хисабы һәм хисаплылык бүлеге муниципаль торак фонды объектларының бухгалтерлык исәбен гамәлгә ашыра.

8. Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе ай саен, 15 числодан соңга калмый түбәндәге форма нигезендә, администрацияләнә торган керемнәрне исәпкә алу буенча хисапны Башкарма комитетның бухгалтерлык хисабы һәм хисаплылык бүлегенә һәм финанс идарәсенә тапшыра:

| Т/с | Бюджет классификациясе коды | Хисап чоры башына сальдо | Исәпләнгән | Күчерелгән | Хисап чоры ахырына сальдо |
|---|---|---|---|---|---|
| | Барлыгы: | | | | |
| | ................ | | | | |
| | шул исәптән: | | | | |
| | - тот түләү | | | | |
| | ................ | | | | |
| | - түләү срогы чыккан бурыч | | | | |
| | ................. | | | | |

9. Башкарма комитетның финанс идарәсе:

1) муниципаль казнадагы торак урыннарын наемга алган өчен түләү күчерү өчен бюджет керемнәре кодын билгели;

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетын формалаштырганда, муниципаль казнадагы торак урыннарын наемга алган

өчен түләүдән кергән акчалар хисабына керемнәр, чыгымнар һәм күп фатирлы торак йортларны капиталь ремонтлауны финанслау өчен Татарстан Республикасының Торак-коммуналь хуҗалыгы фондына җибәрелә торган чыгымнар суммасын күздә тота;

3) хисап ае йомгаклары буенча, «Администратор-Д» программа комплексыннан шәһәр бюджетына керемнәр реестрын Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсенә тапшыра.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова